ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 21 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 3, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3, № 7, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 11 (VI өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 5, № 6 (I өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 55 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяның 7 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“7. Кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы, муниципаль берәмлек тарафыннан гамәлгә куелган оешмаларның хокукый статусын билгеләүче муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр үз көчләренә рәсми басылып чыкканнан (игълан ителгәннән) соң керә.”;

2) 7 статьяда:
а) 8 өлешнең беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“8. Муниципаль берәмлек уставына кертелгән һәм җирле үзидарә органнарының структурасын, җирле үзидарә органнары арасында вәкаләтләр бүлешүне (муниципаль берәмлек уставы федераль законнарга туры китерелгән очраклардан, шулай ук җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затлары вәкаләтләре, аларның вәкаләтләр чоры һәм сайлану тәртибе үзгәрүдән тыш) үзгәртә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр муниципаль берәмлек уставына күрсәтелгән үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертү турында муниципаль хокукый акт кабул иткән

муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре чоры тәмамланганнан соң, муниципаль районның вәкиллекле органы әлеге Законның 22 статьясындагы 3 өлеше яисә $3^1$ өлешенең 1 пункты нигезендә формалашкан очракта – муниципаль берәмлек уставына күрсәтелгән үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертү турында муниципаль хокукый актны имзалаган муниципаль берәмлек башлыгының вәкаләтләре чоры тәмамланганнан соң үз көченә керә.";

б) түбәндәге эчтәлекле $8^1$ өлеш өстәргә:

"$8^1$. Муниципаль берәмлек уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр муниципаль хокукый акт белән кертелә, ул түбәндәгеләр белән рәсмиләштерелергә мөмкин:

1) муниципаль берәмлек вәкиллекле органының (гражданнар җыенының) аның рәисе һәм муниципаль берәмлек башлыгы йә муниципаль берәмлек вәкиллекле органы (гражданнар җыены) рәисе вәкаләтләрен башкара торган муниципаль берәмлек башлыгы берүзе имзалаган карары;

2) вәкиллекле орган (гражданнар җыены) тарафыннан кабул ителгән һәм муниципаль берәмлек башлыгы имзалаган аерым норматив хокукый акт. Бу очракта әлеге хокукый актта вәкиллекле органның (гражданнар җыенының) бу карарны кабул итү турында реквизитлары күрсәтелә. Вәкиллекле органның (гражданнар җыенының) шундый карарына күчеш нигезләмәләре һәм (яисә) муниципаль берәмлек уставына кертелә торган үзгәрешләрнең һәм өстәмәләрнең үз көченә керүе турында нормалар кертү рөхсәт ителми.";

в) түбәндәге эчтәлекле 10 өлеш өстәргә:

"10. Муниципаль берәмлек уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт белән муниципаль берәмлек уставын яңа редакциядә бәян итү рөхсәт ителми. Бу очракта муниципаль берәмлекнең яңа уставы кабул ителә, ә муниципаль берәмлекнең элек гамәлдә булган уставы һәм аңа үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы муниципаль хокукый актлар муниципаль берәмлекнең яңа уставы гамәлгә кергән көннән үз көчләрен югалткан дип таныла.";

3) 15 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле $4^1$ пункт өстәргә:

"$4^1$) җылылык белән тәэмин итүнең бәя зоналарында җылылык белән тәэмин итү объектларын төзүнең, реконструкцияләүнең һәм (яисә) модернизацияләүнең җылылык белән тәэмин итү системасын үстерү, аның ышанычлылыгын һәм энергетик файдасын арттыру өчен кирәкле булган һәм җылылык белән тәэмин итү схемасында аның өчен билгеләнгән чараларын бердәм җылылык белән тәэмин итү оешмасы тарафыннан үтәүгә муниципаль контрольне "Җылылык белән тәэмин итү турында" Федераль законда күрсәтелгән вәкаләтләр кысаларында гамәлгә ашыру;";

4) $15^1$ статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 16 пункт өстәргә:

"16) инвалидлар, сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен физик культураны һәм спортны, адаптив физик культураны һәм адаптив спортны үстерүгә булышлык күрсәтүгә.";

5) $16^1$ статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 14 пункт өстәргә:

“14) инвалидлар, сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен физик культураны һәм спортны, адаптив физик культураны һәм адаптив спортны үстерүгә булышлык күрсәтүгә.”;

6) 17 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле $4^1$ пункт өстәргә:

“$4^1$) җылылык белән тәэмин итүнең бәя зоналарында җылылык белән тәэмин итү объектларын төзүнең, реконструкцияләүнең һәм (яисә) модернизацияләүнең җылылык белән тәэмин итү системасын үстерү, аның ышанычлылыгын һәм энергетик файдасын арттыру өчен кирәкле булган һәм җылылык белән тәэмин итү схемасында аның өчен билгеләнгән чараларын бердәм җылылык белән тәэмин итү оешмасы тарафыннан үтәүгә муниципаль контрольне “Җылылык белән тәэмин итү турында” Федераль законда күрсәтелгән вәкаләтләр кысаларында гамәлгә ашыру;”;

7) $17^1$ статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 17 пункт өстәргә:

“17) инвалидлар, сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен физик культураны һәм спортны, адаптив физик культураны һәм адаптив спортны үстерүгә булышлык күрсәтүгә.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2017 ел, 07 октябрь
№ 75-ТРЗ